**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# «Каравон» рус халык бәйрәмен уздыру турында

Татарстан Республикасы территориясендә ел саен уздырыла торган «Каравон» рус халык бәйрәмен 2019 елда оешкан төстә үткәрүне тәэмин итү максатында һәм «Татарстан Республикасының бәйрәм көннәре һәм истәлекле даталары турында» 1992 елның 19 февралендәге 1448-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы тәкъдимнәрен исәпкә алып, «Каравон» рус халык бәйрәмен 2019 елның 25 маенда Татарстан Республикасы Лаеш районының Никольское авылында уздырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына «Каравон» рус халык бәйрәмен әзерләүдә һәм уздыруда булышлык итәргә.

3. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына «Каравон» рус халык бәйрәменә әзерлекне һәм аны уздыруны массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны оештырырга.

4. Җирле үзидарә органнарына, предприятиеләргә, учреждениеләргә һәм оешмаларга «Каравон» рус халык бәйрәмендә актив катнашуны, аны оештыруда һәм уздыруда ярдәм күрсәтүне тәкъдим итәргә.

5. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2019 ел, 17 апрель
№ ПУ-228